ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

*Симәк авылы* *«22 » апрель 2024 ел.*

**КАРАР №20**

**«Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» («27» сентябрь 2021г. №18 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында карар**

Федераль законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» («27» сентябрь 2021г. №18 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.4 пунктындагы 2.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2.4.1. Адреслашу объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, адреслашу объектына адреслашудан баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле мәгълүматны дәүләт адрес реестрында урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла:

а) кәгазьдә гариза бирелгән очракта - гариза килгән көннән соң 10 эш көненнән дә артык булмаган вакытта;

б) электрон документ формасында гариза бирелгән очракта - гариза кергән көннән соң 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта.";

1.2. 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 2.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карар әлеге объектка яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелә.»;

1.3. 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза белән «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законның 35 статьясы яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә, адресация объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләрен яки комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы. »

1.4. 5 нче бүлекне 5.10 пункты белән тулыландырырга һәм түбәндәге

редакциядә бәян итәргә:
«5.10. Дәүләт (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүнең аерым өлкәләрендә судка кадәр шикаятьләр "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (25.12.2023 ел редакциясе) гамәлгә ашырыла. ».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Садертдинов Р.Ә.**